ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 28.10.2020 г. Казань № 118-11/кс-2020

«ТатСтройКа» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2021 елга салкын су транспортлауга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына туры китереп, салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «ТатСтройКа» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «ТатСтройКа» ҖЧҖ) өчен салкын су транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «ТатСтройКа» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының 28.10.2020
№ 118-11/кс-2020 карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «ТатСтройКа» ҖЧҖ өчен
2021 елга салкын су транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № т/с | Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу белән шөгыльләнүче оешма, муниципаль берәмлек исеме | Салкын суны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр |
| | Зеленодольск муниципаль районы | | |
| 1 | «ТатСтройКа» ҖЧҖ (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 2,92 | 3,14 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге